РЕСПУБЛИКА1 ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
ИСАКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСӘК
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

02.07.2024 №2-88

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә, ТР Буа муниципаль районының Исәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына, Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге Советының 2020 елның 27 маендагы 90-2 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнары белән Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешүләр төзү тәртибенә таянып, Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы тәкъдимен кабул итү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 1-37 номерлы карары нигезендә төзелгән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге Советына шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында килешүгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1.1. 6.1 нче пункт үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«6.1. Әлеге Килешү рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә.».

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге Советына Буа муниципаль районы Советы белән өстәмә килешү төзергә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында рәсми рәвештә басылып чыккан көннән башлап законлы көченә керә http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Исәк
авыл җирлеге башлыгы З.Р.Мөхәммәтҗанова

ТР Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге Советының

2024 елның 27 июнендәге 2-84  номерлы карарына

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге Советына шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында килешүгә  өстәмә килешү

Буа шәһәре « ___» _________ 2024 ел

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы,Устав нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башлыгы __________, алга таба «район Советы» дип аталучы, бер яктан һәм  Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге Советы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы « Исәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эш итүче Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге башлыгы  ____________, икенче яктан, бергәләп «Яклар» дип аталалар, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге Советына вәкаләтләр тапшыру турында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру турында килешүгә түбәндәге өстәмә килешүне төзеделәр:

1. Килешүнең 6.1 пункты Килешүләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Әлеге Килешү рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә.

2. Әлеге өстәмә килешү рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

3. Килешүнең барлык башка пунктлары элекке редакциядә гамәлдә кала.

4. Әлеге өстәмә килешү бер үк юридик көчкә ия булган ике экземплярда төзелгән, һәр як өчен бер экземпляр.

5. Яклар имзасы

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Буа муниципаль районы башлыгы<br>_____________/ | Буа муниципаль районы<br>Исәк  авыл җирлеге башлыгы<br>_______________/ |